| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

РАСПОРЯЖЕНИЕ — БОЕРЫК

13.01.2023 — № 09-р

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылганнарның гаиләләренә ярдәм күрсәтү турында» 2022 елның 10 октябрендәге 656-р номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылганнарның гаиләләренә социаль ярдәм күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

БОЕРЫК БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылганнарның гаиләләренә ярдәм күрсәтү турында» 2022 елның 10 октябрендәге 656-р номерлы боерыгының 1 пунктындагы 1.5 пунктчасына, аны түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәреш кертергә:

«Нурлат муниципаль районы территориясендә муниципаль, дәүләт мәдәният һәм ял учреждениеләренә музейларга, театрларга, концертларга, шулай ук сишәмбе көннәрендә «Грани» кинотеатрынна гаилә әгъзаларына (хатыны, балалары, ата-аналары, әби-бабалары) бушлай бару».

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылганнарның гаиләләренә ярдәм күрсәтү турында» 2022 елның 10 октябрендәге 656-р номерлы боерыгының 1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 1.14 пунктча белән тулыландырырга:

«Муниципаль лагерьларга юлламалар сатып алуда, авыр тормыш хәленә эләккән гаиләләр категориясенә кертүдә беренче чиратны тәэмин итү».

3. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче — З.Р. Сәйфетдинова